Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
29.01.2025 ел №19

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселокта җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон «Җирләү эшен күмү турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогыбашкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 9165,37 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 30.01.2024 ел, № 8 карарын;

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Галлямов